КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 февраль г.Казань № 83

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы өстәмә акчалата түләүләр турында» 2013 ел, 6 февраль, 77 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм югары һөнәри (медицина булмаган) белемле белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы өстәмә акчалата түләүләр турында» 2013 ел, 6 февраль, 77 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 октябрь, 717 нче, 2017 ел, 18 гыйнвар, 13 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм югары һөнәри (медицина булмаган) белемле

белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «җитәкчеләрне,» сүзләреннән соң «, җитәкчеләрнең педагогика эше буенча урынбасарларын» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның өченче абзацында «тәрбиячеләр,» сүзләреннән соң «өлкән тәрбиячеләр,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның көче 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин